КОТКЫ ТУДЫРМАСКА
Министр Марат Җәббаров кибет киштәләренең ни өчен бушап калуын аңлатты
> 2

КЕМГӘ ФАЙДА?
Россия, аның халкы өчен яңадан сыналыр чак җитте
> 2

СӨЛӘЙМАН ГАЛИУЛЛИН:
«Шахмат белән дус булган балалардан менә дигән эшмәкәрләр чыга»
> 3

КЕЛӘМ КҮРСӘТЕР
Газетабызның көрәш бәйгесенә санаулы көннәр калып бара
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 36 (28809) | Чәршәмбе | 16 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ТӘКЪДИМ БАР, ИХТЫЯҖ ЮК?

Вазгыять

Башкортстан депутатлары туган телләрне укыту буенча «Мәгариф турында»гы Законга үзгәрешләр кертү тәкъдиме белән чыгарга җыена. Авторлар фикеренчә, милли телләрдән БДИга алмаш булырдай сынау кирәк. Бүген укучыларга туган телләрдән имтихан бирү мөмкинлеге бармы?

Башкортстан депутатлары туган телләр һәм әдәбиятлардан дәүләт имтиханының форматын үзгәртергә тәкъдим итә. БДИ үрнәгендә сынау нәтиҗәләре вузларга кергәндә исәпкә алынырга тиеш дигән фикердә алар. Әлеге адым туган телләрне өйрәтүне дә киңәйтергә ярдәм итәчәк. Мондый фикерне илнең ун төбәгендә хуплаганнар. Җирле закон чыгаручылар, проектка үзгәрешләр кертүне раслап, тәкъдимнәрен Дәүләт Думасына җибәрәчәк.

Башкортстан укытучысы Галия Корбанова «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы – 2021» бөтенроссия бәйгесендә җиңгән иде. Бу тәкъдимгә карата аның фикерен белештек.

– Безнең мәктәптә 9 нчы сыйныф укучылары арасында әлегә кадәр туган телдән имтихан бирергә теләк белдерүче булмады. 11 нче сыйныфта татар теле бөтенләй укытылмый. Бер яктан, депутатлар фикере белән килешәм. Бәлки, имтихан бирү катгый саналса, туган телләрне өйрәнү сыйфаты яхшырыр, тиешле күләмдә сәгатьләр саны булыр иде. Икенче яктан, имтихан бирәчәксең, дип кенә укучыны кызыксындырып булмаячак. Без, киресенчә, туган телгә нәфрәт уятырга мөмкинбез, – ди Галия Корбанова.

Туган тел мәсьәләсендә Татарстан җитәкчеләре дә кул кушырып утырмый. Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында мәгариф министры Илсур Һадиуллин да шул проблемаларга тукталды. Киләсе уку елында кертеләчәк яңа стандартларда туган телләр укыту планының мәҗбүри өлешендә булса да, программаларның кайбер вариантына туган тел һәм туган тел әдәбияты дәресләре кермәгән. «Башлангыч мәктәп өчен укыту программасының алты варианты әзерләнгән. Шуларның икесендә туган телләрне өйрәнү атнасына 1–2, милли мәктәпләрдә 3 сәгать каралган. Калган өчесендә туган тел һәм әдәбиятны укыту кермәгән. Татарстан Президенты исеменнән Россия мәгърифәт министрына барлык вариантларга да туган телләрне кертү тәкъдиме белән чыктык», –диде Илсур Һадиуллин.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе башлыгы Лилия Әхмәтҗановадан туган телләрдән имтихан бирү тәртибе турында сораштык.

– «Россиядә мәгариф турында»гы Законда, гомуми белем бирү оешмаларында туган телләрне өйрәнүчеләр өчен имтихан бирүне төбәкләр оештыра, диелгән. Бездә 9 нчы сыйныфтан соң йомгаклау имтиханнары, 11 нче сыйныф укучылары өчен бердәм республика имтиханы (БРИ) үткәрелә. Тугызынчылар арасында туган телләр һәм, билгеле, татар теленнән имтиханны 1500 бала тапшыра. Чуаш, удмурт, мари телләреннән безгә биремнәрне Чувашия, Удмуртия, Мари Иле республикалары эшләп бирә. Без үзебез исә татар теленнән эшләп җибәрәбез. Монда проблема юк, проблема башкада, – ди Лилия Әхмәтҗанова.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Белгеч искәртүенчә, бала бердәм дәүләт имтиханын югары уку йортына керү өчен сайлый. Бүген вузларга укырга керү өчен туган тел бер генә уку йортында да имтихан буларак кабул ителми. Россиядә барлыгы 74 тел укытыла. 43 уку йортында туган телләр буенча укытучылар әзерләнә, ләкин берсенең дә кабул итү өлешендә туган тел һәм әдәбият юк. Кызганыч, Россия Фән һәм югары белем министрлыгының «Бакалавриат һәм специалитет программалары буенча укырга кабул иткәндә керү сынаулары исемлеген раслау турында» 30.08.2009 ел, 666 нчы боерыгы белән расланган керү сынаулары исемлегендә туган тел һәм (яки) әдәбият буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре исәпкә алынмый.

Татар теле юнәлешенә керү өчен уку йорты тарих, җәмгыять белеме, рус әдәбияты кебек фәннәрне үзе сайлап ала.

– Без Россия Фән һәм югары белем министрлыгына журналистика, культурология, театр сәнгате, туган тел укытучылары әзерләү, филология юнәлеше исемлегенә «туган тел һәм әдәбият» фәнен кертүне сорап мөрәҗәгать иттек. Боерыкка үзгәреш керткән очракта, югары уку йортлары имтихан буларак «Туган тел һәм әдәбият» фәнен дә керү сынавы итеп таныр иде. Җавапта, уку йортлары өстәмә имтихан буларак «туган тел һәм әдәбият» фәннәреннән сынау куя ала, дип күрсәтелде. Әмма бу чишелеш түгел. Бу – өстәмә сынау, өстәмә имтихан. Бүген нәкъ менә югары уку йортына керү сынаулары исемлеген «туган тел һәм әдәбият» фәне белән тулыландыру сорала, – ди Лилия Әхмәтҗанова. – Республиканың ректорлар советы, КФУ белән бу хакта киңәшмәләр уздырылды. Исемлектә «туган тел» булган очракта, бала аны һичшиксез сайлап алачак. Быел 11 сыйныфтан соң ике бала татар теленнән сынау бирергә теләк белдерде. Алар татар филологиясе бүлегенә укырга бара. Быел КФУ кабул итү комиссиясе карары белән татар теленнән бердәм республика сынавын эчке имтихан белән тәңгәлләштерәчәген белдерде.

КФУның татар теле белеме кафедрасы мөдире Гөлшат Галиуллина әйтүенчә, тәкъдим булу яхшы, әмма без бу юлга ничә бала белән чыгачакбыз?

– Республикада туган телдән бердәм республика сынавы бар. Моңа кадәр югары уку йортына аның нәтиҗәләре буенча кабул иткән идек, тик узган ел абитуриентлар эчке имтихан биреп керделәр. Моны яңалык дип әйтеп булмый. Шунысы борчый: туган телдән республика имтиханнарын бирүчеләр елдан-ел кими бара. Имтиханы булыр, әмма аны тапшырырга баласы булмас. Менә шуны күз уңында тотарга иде, – ди Гөлшат Галиуллина.

Сәрия МИФТАХОВА

Көннәре һәм күләме билгеле

Рамазан ае башлану һәм тәмамлану вакыты билгеле. Бу хакта Татарстан мөфтияте Казыйлар шурасы чираттагы утырышында хәбәр ителде. Моннан тыш тәравих намазында укыла торган рәкәгатьләр саны, фидия һәм фытыр сәдакалары күләме билгеләнде.

Шулай итеп, 1 апрельдә ястү намазыннан соң беренче тәравих намазы укыла, 2 апрель (шимбә) – уразаның беренче көне. 30 апрельдә – соңгы тәравих намазы, 1 майда (якшәмбе) – уразаның соңгы көне булачак. 2 майда мөселманнар Ураза бәйрәмен билгеләп үтәчәк.

Дин әһелләре нисаб, фытыр һәм фидия сәдакалары күләмнәре турында да әйтте. Зәкят түләү өчен нисабны 620 мең сум күләмендә билгеләделәр (алтын буенча). Фытыр сәдакасы түләү өчен нисаб – 58 мең сум (көмеш буенча). Фытыр сәдакасы – 150 сумнан, ә зәкят чыгару мөмкинлеге булганнарга 800 сум итеп түләргә тәкъдим ителә.

Моннан тыш, сәламәтлегенә бәйле рәвештә ураза тотмаган һәм аны башка вакытта да каза кылып үти алмаучыларга һәрбер көн өчен 300 сум күләмендә фидия билгеләнде.

Тәравих намазы барлык мәчетләрдә 20 рәкәгать итеп укылачак.

Онлайн гына булмый

Татарстанда электрон рәвештә «больничный» рәсмиләштерү мөмкинлеге туктатылды. Хәзер документны хастаханәдә табиб тикшерүе узганнан соң гына алырга була.

Исегездә булса, дистанцион рәвештә «больничный» рәсмиләштерү 10 февральдән башланган иде. Бөтен ил буенча бу система 15 мартка кадәр гамәлдә булды. Сүз уңаеннан, шул дәвердә 2,5 меңләп Казан кешесе «больничный» кәгазен өйдән чыкмыйча гына рәсмиләштергән.

Шикаять бирү гадиләшә

Россия машина йөртүчеләренә юл йөрү кагыйдәләрен бозган өчен штрафны онлайн рәвештә шикаять итәргә (обжаловать) рөхсәт бирделәр. Моның өчен «Госуслуги Авто» дигән махсус мобиль кушымта кирәк булачак.

Куллану кагыйдәсе бик гади: кушымтаны ачып, штраф түләү бүлегенә керергә һәм шунда ук шикаять бирергә җыенган штрафны сайларга кирәк. Алга таба кулланучыга шикаять бирү сәбәбен сайларга һәм аны расларлык кирәкле мәгълүматны урнаштырырга кушылачак.

Шунысы мөһим: ЮХИДИ камералары теркәгән штраф өчен генә шикаять бирү мөмкин. Мөрәҗәгать 10 көн эчендә карала, ул арада өстәмә мәгълүмат соратулары да ихтимал.

Сорау – җавап

Артыгы – иясенә

Торак-коммуналь хуҗалык хезмәте өчен килгән «сәлам хаты»н укып, кайчагында өнсез дә каласың. Янә исәпләп, түләргә дигән сумманың нигезсез артуын күрсәң, бигрәк тә күңелсез булып куя.

Әмма андый очракта акчаны кире кайтару ысулы бар икән. Моның нигезе булып Россия Торак кодексының 157 нче маддәсе («Коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме». – **Ред.**) тора.

Әгәр коммуналь хезмәтләр өчен түләү чынлап та нигезсез рәвештә арттырылган икән, торак милекчесе яңадан исәпләүне генә түгел, арттырылган сумманың 50 проценты күләмендә акча да таләп итәргә мөмкин. Бу шәһәр фатирында яшәүчеләргә дә, үз йортында торучыларга да кагыла.

Арттырып түләгәнсезме, әллә юкмы? Моны ачыклау өчен, төбәктәге норматив һәм тарифлар белән танышырга кирәк. Аннан исә идарәче компания белән килешүне укып чыгарга. Барысы да чагышамы? Хаталар, сезнең өчен аңлашылмаган саннар, искәрмәләр юкмы? Булган очракта, идарәче компания белән аларга җавап табарга кирәк. Квитанциядә барысы да дөрес икән, ни өчен һәм күпме түләвегезне булса да белеп торырсыз. Хәтер яңарту комачау итми.

Хата табылса, нишләргә? Бу очракта хезмәт күрсәткән оешмага гариза язарга кирәк булыр. Гадәттә,

мөрәҗәгатьне бер ай дәвамында карыйлар, шуннан соң рәсми җавап бирәләр.

Әгәр дә хезмәт күрсәтүче үз хатасын таный икән, штраф түләячәк. Матди компенсацияне түләү өчен аңа гариза тапшырылган көннән алып ике ай вакыт бирелә. Өстәвенә компенсация акчалата гына түгел, ә алдагы түләүләрне яңадан исәпләп бирү рәвешендә булырга да мөмкин.

Шулай да, бу саннарның ничек барлыкка килүен, нәрсә өчен икәнен аңлату белән генә дә чикләнергә мөмкиннәр. Бу әле алар алдый дигән сүз түгел. Күңелдә шик туа, хата бар дип саныйсыз икән, торак инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Кайсы очракта штраф түләнми? Әлбәттә, әгәр дә хезмәт күрсәтүче хатаны үзе табып, аны бетерү җаен кайгыртса, штраф түләттереп булмаячак.

Әгәр коммуналь хезмәт өчен түләүне исәпләүдә хата милекче гаебе белән килеп чыккан икән (әйтик, счетчиктагы мәгълүматны дөрес күрсәтмәгән), бу да матди компенсация даулау өчен сәбәп түгел.

САН

2021 ел ахырына Россиядә яшәүчеләрнең торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен түләү буенча гомуми бурычы 15 процентка кимегән. Әҗәтнең иң аз күләме – сентябрьгә, иң зур күрсәткече февральгә туры килгән.

Сүзгә-сүз

Динә ЛАВРИКОВА, «Нәфис Косметикс» предприятиесе генераль директоры:

Узган ел Латвиядән алып Һиндстанга һәм Кытайга кадәр товар белән тәэмин иттек. Житештерү куәтләре буенча запас бар. Әгәр кирәк булса, Татарстанны гына түгел, бөтен илне көнкүреш химиясе белән тәэмин итә алачакбыз.

(Казан мэриясе сайтыннан)

РОССИЯДӘ – АКЧАНЫ САК ТОТУ

Россиядә мая туплаучылар саны март аенда 81 процентка җиткән. Февраль аенда бу күрсәткеч 68% иде. Моны Илкүләм финанс тикшеренүләре агентлыгы белгечләре ачыклаган.

АКЧАНЫ НИЧЕК САКЛЫЙЛАР?

16% мая туплауны кирәк дип санамыйм

29% кулга акча керүгә, бер өлешен саклыйм, ә калганын чыгымнарга тотам

52% башта табышны кирәк-яракка тотам, калган өлешен саклыйм

Атна җылы тәмамлана

Бу атна азагына Татарстанда 1 градуска кадәр җылытыр дип көтелә. Гидрометеорология үзәге мәгълүматларына ышансаң, алдагы ике көндә явым-төшемнәр көтелми. Төнлә һәм иртән һава температурасы 19 градуска кадәр суытачак. Көндез –3...–10 градус тирәсе суык булачак.

18 һәм 19 мартта төнге һава температурасы –18...–13 градус булачак, ә көндез –4тән +1 градуска кадәр күтәрелер дип фаразлана. Атмосфера фронты якын булу сәбәпле, урыны белән бераз кар явачак.

kzn.ru



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ДИПЛОМАТЛАР РОССИЯГӘ ҺӘМ КЫТАЙГА КАРШЫ

Көнбатышның Россиягә каршы юнәлдерелгән икътисад сугышы көннән-көн киңрәк җәелә. Вашингтон һәм Брюссель бу тартышны бөтендөнья масштабына җәелдерергә тырышалар. Һөҗүмнең төп юнәлеше соңгы көннәрдә Кытайга каршы борылды. Алар Мәскәүгә каршы блокадага кушылмады, чагыштырмача нейтралитет саклады. Дөрес, чин банклары үз эшләрен санкцияләр кысасында алып барырга тырышалар, чөнки ни генә дип әйтмә, планета масштабындагы финанс агымнары – американылар контролендә. Америкадан торып, дөньяның теләсә кайсы иленә матди зыян салып була. Таякның икенче башы Вашингтонның үзенә дә суга сугуын, әмма бүген Җир шарында вазгыять шундый: финанс мафиясе югалтулар белән бик исәпләшеп тормаска булды. Туры мәгънәсендә яшәү – үлем мәсьәләсе хәл ителә, без моны аңларга тиешбез.

Кытай икътисады Россия белән дә, АКШ белән дә тыгыз бәйләнгән. Пропорцияләр чагыштырырлык түгел, билгеле. Белгечләр Күк асты иле матди яктан 75 процентка Америкага бәйле, диләр. Әле тагын океан арты белән аркадашлык итүче Европа, Канада бар. Болар белән конфликтка керү Азия гигантына зур югалтулар китерергә мөмкин. Каршы як өчен дә шулай ук. Шул сәбәпле ике як та килеп туган каршылыкларны дипломатик мәйданда хәл итәргә тырышалар. Дүшәмбе көнне Римда «Астория» кунакханәсендә АКШ Президентының милли куркынычсызлык буенча киңәшчесе Джейк Салливан белән Кытайның тышкы сәясәт өчен җаваплы төп чиновнигы, Компартия Үзәк Комитетының Тышкы эшләр канцеляриясе җитәкчесе Ян Цзечи очрашты. Сөйләшү барышы турында да, нәтиҗәләре хакында да матбугат вәкилләренә берни дә әйтелмәде. Әмма Салливанның очрашу алдыннан ясаган белдерүләре теманың Россия – Украина конфликтына кагылышлы булуын аңлата. Аналитиклар АКШ дипломаты Кытай ягына, санкцияләрне әйләнеп үтеп, Россиягә ярдәм итмәскә дигән күрсәтмә бирде дип саныйлар. Италия саммиты алдыннан Financial Times газетасы, Ак йорттан алынган мәгълүматка таянып, Россия Кытайга ярдәм, шул исәптән хәрби техника белән дә ярдәм сорап мөраҗәгать итте дигән хәбәр таратты. Путин сүзчесе Песков, Россиянең хәрби хәрәкәтләр алып барырга резервлары җитәрлек дип моны кире какса да, Кытай җитәкчеләре Мәскәүгә хәрби ярдәм күрсәтмәячәкләрен ассызыкласалар да, Вашингтон алар сүздә генә үзләрен шулай тоталар, чынбарлык башкача дип бара. Кытайга ни рәвешле басым ясаячакларын океан артында яшерәләр. Мөмкинлекләре чикләнгән дип уйлыйк, чөнки дөньяның зурлыгы ягыннан икенче икътисады түнсә, барыбыз да егылачакбыз. Егыласы урынга салам түшәп кую да булышмаячак. Пекин мөмкин булганча санкцияләр кысасында эш итә кебек. Әйтик, Россия самолетларына запчастьлар бирүдән баш тартты. Әмма төньяк күршесе белән элемтәләрне тулысынча өзү Кытай файдасына түгел. Анда болай да көчле икътисади кризис адымнарын тизләтә. Кыйммәтле кәгазьләр базарында соңгы көннәрдә чин компанияләренең кәгазьләре мәтәлчек ата. Кытай бизнес-гигантлары дефолтка килеп терәлделәр. Үзара түләүләр кичектерелә. Россия резервларының байтагы Кытай юаньнарында саклана. Бу резервлар да янса, хәл авыр булачак. Америка басымыннан башка да эшләр мөшкел әле монда.

Россиядә

КЫТЛЫКТАН КОТЫЛЫП БУЛЫРМЫ?

Бүген дөньяда барган тартышның нәтиҗәләрен без үз җилкәбездә бик әйбәт татыйбыз. Көрәш бөтен мәйданнарда да бара. Мәгълүмат кырында аеруча көчле. «Свободная пресса» дип аталган, әмма элек-электән үзенең караһругчыллыгы һәм ура-патриотизмы белән танылган сайт нилектәндер 6 марттан башлап яңа материаллар элми. Илнең күп кенә рәсми сайтлары да киберһөҗүмнәргә дучар булалар һәм ачылмыйлар. Тыелган сайтлар хакында сүз дә бармый. Газета хәбәрчесе компьютерына vpn куеп тормады, объектив мәгълүматны болай да табып була дип саный. Вәләкин сишәмбе иртәсендә мәгълүмат алу өчен федераль хөкүмәтнең рәсми газетасы – «Российская газета» сайтына керә алмады. Хәрби цензура шартларында теләсә ни язып булмый бит инде, штраф түләргә кесәдә акча да юк. Әле ярый, кайчандыр Роскомнадзор бикләргә азапланып, теше үтмәгән «Телеграм» карусыз эшли. «Российская газета» каналы да, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановныкы да, хәтта «Путин «Телеграмда» дигән канал да безгә рәсми мәгълүматны шуның аша җиткереп торалар. Тик «Телеграм»да да проблемалар бар икән. «Российская газета» каналы кулланучыларның фото һәм видеолар куюда кыенлыкларга тап булуын хәбәр итә. Соңгы көннәрдә мәгълүм социаль челтәрләр бикләнү сәбәпле, бик күп кеше «Телеграм»га агылды. Сәбәп, бәлки, шундадыр.

Ахыр чиктә «Телеграм»сыз да яшәп булыр иде ул. Соңгы көннәрнең вазгыяте безне матди кыенлыклар кочагына ыргыта. Федераль хөкүмәт газетасы каналында икътисадчы Алексей Зубец дигән әфәнде якындагы айларда кибет киштәләре бушарга мөмкин дип хәбәр итә. «Әлегә, – ди ул, – ваклап сату челтәрләре санкцияләргә кадәр туплап калдырган запасларга таяналар. Агымдагы запаслар беткәч, яңалары әле килеп җитмәгән бер вакытта товарлар җитешмәве булачак», – ди ул. Әмма белгечнең фаразы яхшы: бу хәл озак дәвам итмәячәк. Рөстәм Миңнеханов каналы да шикәр кытлыгы мәсьәләсен кузгата. Ул складларда шикәр күп икәнен үз күзләре белән күреп хәбәр итә. Ләкин паникага ияргән халык шикәрне кибет киштәсенә килүгә алып бетерә. Ажиотаж бәяне дә күккә чөя, кытлык та тудыра. 1991 елгы вазгыять югарырак ноктада кабатлана ягъни. Хәзер кыйммәт тә, юк та. Инде социаль челтәрләрдә шикәрне башка товарларга бартер нигезендә алыштыручы төркемнәр пәйда була башлады, диләр. «Кара базар»да валюта сәүдәсе оештыручылар да үз төркемнәрен булдыралар. Валюта түгел, рус сумы да кесә төбендә генә калды әле монда. Бу шаукым коронавирус дулкыны кебек үк үтеп китәр дип өметләник. Азык-төлек җитәрлек, ашкынуны гына туктатырга кирәк. Бу юллар язылганда, хатын кибеттән кайтып керде. Авыл кибетендә кытлык юк, кирәкле бар нәрсә дә бар. Халык шикәр һәм онга тиенгән, ярма һәм үсемлек маена да ихтыяҗ юк, күпләп чәй алалар, диде.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Татарстанга килүче туристлар саны ике мәртәбә артачак. Республика һәм «Туризм.РФ» килешүе моңа мөмкинлек бирәчәк. Татарстан Президенты Мәскәүдә корпорация белән төбәкнең туристик инфраструктурасын үстерү турында килешү имзалады.

– Бу – бик мөһим килешү, – диде чарада катнашкан Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко. – Татарстан – хәзер шактый алга киткән туристик төбәк. Әмма без республиканың бу юнәлештә көчен күрәбез. Тармак үсешенә зур игътибар биргән Рөстәм Миңнехановка рәхмәт әйтәбез. Хәзер республикага килүче туристлар саны 3,5 миллионны тәшкил итә. Кирәкле инфраструктураны булдыру нәтиҗәсендә, бу сан ике мәртәбә артачак.

Дмитрий Чернышенко Россия Президенты Владимир Путинның төбәкләрдә тармак инфраструктурасын үстерүне тизләтергә кушуы турында да искә төшерде. Сүз уңаеннан, хәзерге шартларда да хөкүмәт туризм өлкәсенә матди ярдәм күрсәтүне туктатмый.

– Татарстан һәрвакыт туристлар өчен кызыклы иде. Узган ел безгә 3,3 млн кеше килде. Без пандемиягә кадәр күрсәткечләргә кайттык диярлек. 2019 елда республикада 3,6 млн кеше кунак булды. Татарстанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасының өч корылмасы урнашкан, моннан тыш без авыл туризмын үстерәбез, – диде Татарстан Президенты.

«Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проекты кысасында Татарстанда биш туристик юнәлешне үстерү ниятләнә. Бу – «Идел буе Болгары», «Соколка», «Зөя утраушәһәрчеге», «Кама Тамагы» һәм «Лаеш». Беренчесе «Идел буе буенча сәяхәт» проектына кертелде. Димәк, аны тормышка ашыру Идел буе федераль округының тагын 6 төбәгендәге туризм тармагы үсешен куәтләп җибәрәчәк, кунаклар санын арттырачак.

– Уртак проект нигезендә республикада кунакларны заманча, сыйфатлы һәм уңайлы урнаштыру чаралары төзү бурычы тора. Шулай ук Төзелеш министрлыгы, башка федераль хакимият органнары белән бергә туристик проектларны һәм юллар мәсьәләсен хәл итәчәкбез, – дип шәрехләде «Туризм.РФ» генераль директоры Сергей Суханов.

ЯШЬЛӘР ДӘ ИШӘЯ

Төбәкләрдәге яшь парламентарийлар берләшергә тели. Татарстан Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты утырышында аның вәкилләре шул хакта Фәрит Мөхәммәтшинга әйтте. Дәүләт Советы Рәисе тәкъдимне хуплады.

– Минемчә, бу дөрес һәм кирәкле. Ул безнең яшьләрнең ачык һәм демократик берләшүенә ярдәм итәчәк, – диде ул.

Утырышта яшьләр эшкуарлыгына дәүләт ярдәме һәм социаль стипендия түләү мәсьәләләре буенча фикер алыштылар, яшьләр сәясәте турында Федераль законны камилләштерү буенча тәкъдимнәр барланды, шулай ук 2021 елдагы эшкә йомгак ясап, киләсе елга бурычлар билгеләнде.

Аерым алганда, Татарстанның яшь парламентарийлары «яшь галим» төшенчәсен закон нигезендә теркәргә тәкъдим итә. Эшкуарларга да ярдәм кирәк. Дөресрәге, ярдәм чаралары турында күбрәк сөйләргә. Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, күпчелек (80 процент!) дәүләт чаралары турында бөтенләй белми. Шуннан чыгып, бизнес башларга теләп тә, куркып калганнары күпме икәнен чамалау кыен түгел. Хәзерге вакытта профильле комиссия әгъзалары яшьләр эшкуарлыгына дәүләт ярдәме чараларының электрон исемлеген булдыру юнәлешендә эшли.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин яшь коллегаларының эшен мөһим дип атады. Алай гына да түгел: хәзерге «зурлар» парламентындагы депутатлар, министрлык вәкилләренең күпчелеге әлеге мәктәпне узган. Димәк, үсеш өчен этәргеч тә бар, кемгә карап үрнәк аласы да билгеле. «Республиканың Яшьләр парламенты күптәннән фикер алышу өчен абруйлы мәйданчыкка әйләнде. Биредә яшьләрне борчыган мәсьәләләр дә, Татарстанның социаль-икътисади үсешенә бәйле сораулар да күтәрелә», – диде Фәрит Мөхәммәтшин бу җәһәттән.

Сүз уңаеннан, утырыштан соң Фәрит Мөхәммәтшин Россия Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Олег Машковцев, Түбән Новгород өлкәсе Закон чыгару җыены рәисе, Идел буе федераль округы Закон чыгаручылары ассоциациясе координаторы Евгений Люлин һәм округның Яшьләр парламентлары җитәкчеләре катнашында эшлекле киңәшмә уздырды. Әлеге утырышта Идел буе федераль округы Яшьләр парламентлары ассоциациясен булдыру мәсьәләсе турында җентекләп фикер алыштылар. Евгений Люлин хәзерге вакытта сәяси мәйданда яшьләрнең дә күп булуын ассызыклады. «Ассоциация булдыру тәкъдиме яшь парламентарийларның үзләреннән чыгуы аеруча куанычлы. Бу мәсьәлә Идел буе федераль округы Закон чыгаручылар ассоциациясенең 63 нче утырышына чыгарылачак», – диде ул.

Кемгә – война, кемгә – файда

Сәяси сәгать

Бу әйтемнең русчасы «Кому – война, кому – мать родна». Фаразлауларынча, ул Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында телгә кергән һәм бүгенгә хәтле үзенең төп мәгънәсен югалтмый.

Швейцария тарихчысы Жан-Жак Бабель исәпләвенчә, безнең эрага хәтле 3500 елдан башлап бүгенгә хәтле кешелек дөньясы нибары 292 ел тыныч, ягъни сугышларсыз яшәгән. Бу – тарихи вакыт белән исәпләгәндә, бер мизгел генә. Бәндә баласына һаман нидер җитмәгән.

Бу язмага тотыныр алдыннан сугышлар тарихын бераз барлап утырдым. Әлбәттә инде, мине Америка кызыксындырды. Ул Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң гына да Европа, Азия, Африка, Латин Америкасының алтмышлап илендә бертуктамый сугышлар алып барган. Шунысы кызык (кызыктырмы инде бу): Гражданнар сугышын исәпләмәгәндә, Американың үз җирендә бүтән бернинди сугыш та булмаган, әмма бөтен җиргә борын тыгып яшәгән һәм яши ул. Үзе яулап алган колонияләрдә төзелгән бу дәүләтне чын мәгънәсендә «агрессор» дип бәяләргә булыр иде. Украинада махсус хәрби операция башлангач, Россия Президенты Путин Америкага «Империя зла» дип бәя биргән иде. Кушма Штатлар бу «исем»не гомер буе аклап килә кебек. Әле дәүләт булып оешканчы, 1622 елда ук җирле халык – индеецларга каршы сугыша башлый Америка һәм сугыш ике гасыр дәвам итә. Сүз уңаеннан әйтик әле, бу мәсьәләдә Англия дә үзен шактый танытып, «колониалист» исемен алган иде. АКШ белән Англия бүген дә бер тәртә арасында, гәрчә, 1812–1814 елларда Америка белән Англия үзара сугыш алып барсалар да. Сугышның төп сәбәбе – индеецларның җирләрен яулап алу.

АКШ белән СССР (Россия) арасында каршылыкның һич бетәсе юк кебек. Бу – ике система арасындагы олы ызгыш. Әле без малай чакта, Никита Хрущев заманында «Американы куып җитик һәм узып китик» дип язылган плакатлар хәтта авыл җирләрендә дә күзгә чалына иде. Галәмгә беренче космонавт очыруыбыз шул узып китәргә тырышуның бер галәмәте иде. Еллар узган саен ике арадагы каршылык яңа төсмерләргә баеды. Шуның берсе – Американың төрле илләрдә демократик җәмгыять урнаштырып йөрергә маташуы, шул исәптән, бездә дә. Шунысы сәер: бу «изге» омтылыш нигәдер төрле диверсияләр белән үрелеп бара.

Рәсми мәгълүматларга караганда, 1945–1991 елларда Америка СССРның һава чикләрен биш мең мәртәбә боза, 140 тапкыр десант төшерә. Сүз уңаеннан, СССР союзнигы исәпләнгән Америка Гитлер Германиясе белән сугышта шактый баеп кала.

Сугыш чыгарып, корал сату – аның өчен шактый уңышлы бизнес, күрәсең. Бүген махсус хәрби операцияне Россиянең Украинага бәреп керүе дип бәяләүчеләр дә бар. Бу урында сәяси эксперт Яков Кедминың (Яков Казаков) кайбер фикерләрен телгә аласы килә. Яков Иосифович Казаков – Израиль Тышкы эшләр министрлыгында «Рус бүлеге»н җитәкләгән кеше, бүген дә Израильдә яши. Аның фикеренчә, Украинадагы хәлләр – Көнбатышның Россияне юкка чыгару өчен алып барган сугышы. Украина исә – Көнбатыш кулында марионетка гына. Аның үз дәүләтчелеге юк. Бер генә мисал: 2016 елда, әле вице-президент чагында Джозеф Байден Украинаның генераль прокуроры Виктор Шокинны 6 сәгать эчендә эшеннән алдыртты. Мондый хәлнең кайсы дәүләттә булганы бар? Кыскасы, Украинаның кем кулында курчак икәне артык җәелеп сөйләмәсәң дә, аңлашыла. Без телгә алган Яков Кедми Украинада башланган хәрби операцияне болайрак бәяли: «Россия, зур түземлелек күрсәтеп, Көнбатыш илләре белән сөйләшүләр алып барырга тырышты, әмма Көнбатыш аны аңларга теләмәде. Россия аларга (АКШ дип аңлыйк. – **Ред.**) яшәргә комачаулады. Америка бары тик үз законнарын гына таный. Көнбатышны намуслы булырга чакыруның файдасы юк».

Россиягә басым ясау өчен Украина иң яхшы плацдарм иде. Беренчедән, Россия белән чиктәш. Икенчедән, ул урталай бүленгән, бер өлеше – Көнбатышка, икенчесе Көнчыгышка караган ике идеологияле ил. Соңгы берничә дистә ел эчендә Көнбатыш идеологиясе украиннарның баш мие күзәнәкләренә тирән үтеп керде. Анда Россияне, русларны күралмаган, рус цивилизациясен Җир йөзеннән юк итәргә әзер торган яңа буын тәрбияләнде. Геноцид кешелеккә каршы иң зур җинаять санала. Бүген Украина неофашистлары: «Путинны үтерергә, рус халкын, Россияне юк итәргә кирәк!» – дип ачыктан-ачык әйтәләр икән, иң зур җинаятьче кем булып чыга соң? Мондый чакырулар Икенче Бөтендөнья сугышы алдыннан фашистлар телендә иде.

Бүген Украинаның атом-төш коралы белән мактануы, анда Американың биологик лабораторияләре табылуы һәм АКШның моны тануы, Европа илләренең Украинага күпләп-күпләп сугыш кораллары сатуы, яллы гаскәр кертелүе – барысы да хәлләрнең үтә киеренкеләнүен раслый. Бу ызгышта бөтен халыкара нормалар бозыла. Кеше хокуклары буенча Женева конвенциясен генә алыйк. 1949 елда кабул ителгән бу документта дүрт халыкара килешү, өч өстәмә беркетмә булып, анда сугыш хәрәкәтләре вакытында тыныч халыкка зыян китермәү, каршылык күрсәтә алмаучы солдатларга, ягъни яралыларга һәм әсирләргә кешелекле мөнәсәбәт күрсәтү кирәклеге язылган иде. Украина ызгышында конвенциянең «к» хәрефе дә үтәлми, ә АКШ һәм Европа илләре ерткычлыкларны дәшмичә хуплыйлар.

Минем бер танышның туганнары Украинада яши. Әле махсус операция башланганчы ук туганнары аңа: «Инде ничә ай киенеп йоклыйбыз, гел шартлау да атыш», – дип хәбәр салган булганнар. Неофашистлар бүген үз халкын үтерә, шәһәр-авылларны утка тота-тота чигенә. Басуларда – мина кырлары. Димәк, җитәкчелеккә үз җире дә, үз гражданнары да кирәк түгел. Һәм «Гордиев узел»га, ягъни үтә дә чияләнеп беткән төенгә кемдер балта белән чабарга тиеш иде. Борынгы грек мифологиясе буенча бу төенгә Александр Македонский кылыч белән чапкан, диләр. Инде менә Россиягә тарихны кабатларга туры килде. Россия, аның халкы өчен яңадан сыналыр чак җитте. Кеше арасында төрле фикерләр йөри, бәлки, неофашизмны яклап, өстәл астында кул чабулар да юк түгелдер. Мәгълүмати сугыш кешеләрнең башларын шактый ук бутап та бетерде. Без махсус операциянең күпмегә сузыласын фаразларга җыенмыйбыз. Әмма Украинадагы хәлләрнең Россиягә янавы хак иде. Психология фәненнән билгеле булганча, саклануның иң яхшы ысулы – һөҗүм итү, һәм бу тактиканы күп илләр кулланган.

Россиянең махсус операция башлавы да рус цивилизациясен, Россия иминлеген саклау өчен. Һәрхәлдә, үзем шулай кабул итәм.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

МАРАТ ҖӘББАРОВ:

«БӘЯЛӘР ҮСЕШЕ КОТЫЛГЫСЫЗ»

Бер атна эчендә республикада шикәргә ихтыяҗ – 16, көнбагыш маена – 9, карабодайга – 5, тозга 7 тапкыр арткан. Шуңа карамастан, складларда ким дигәндә ике айга җитәрлек азык-төлек бар. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров Хөкүмәт йортында узган брифингта журналистларга шулай дип хәбәр итте.

– Нәкъ менә шушы ыгы-зыгы аркасында шәһәрләрдәге сәүдә нокталарында буш киштәләр күрергә туры килә. Бүгенгә вазгыять тотрыклылана, кибетләрдә запаслар арта, – диде министр.

Аның сүзләренчә, кибетләрдәге товар кытлыгы да, бәяләрдәге үзгәрешләр дә министрлыкларның һәм тикшерү органнарының катгый күзәтүе астында тора. Телибезме-теләмибезме, ихтыяҗ арту бәяләр күтәрелүенә дә китерә. Министрлык китергән мәгълүматлар буенча, узган айда, мәсәлән, шикәр бәясе – 6, сөт – 6,6, атланмай – 3,1, помидор – 11,8, кишернеке 10,3 процентка арткан. Әле бу соңгы атнадагы үзгәрешләрне исәпкә алмаганда гына. Ләкин Идел буе федераль округындагы башка төбәкләр белән чагыштырганда, кайбер позицияләр буенча Татарстанда бәяләргә тотрыклылык саклана. Мәсәлән, сөт бәяләре үзгәрешсез калган.

– Бәяләр үсеше котылгысыз. Предприятиеләр аны арттырмыйча да булдыра алмый, чөнки кайбер чимал, мәсәлән, шул ук ипине генә алсак та, ингредиентлары чит илдән кайтарыла. Аларны бүген үзебезнекеләр белән алмаштырырга кирәк, – дип белдерде Марат Җәббаров.

Министр сүзләренчә, иске партиядәге шикәр бәяләре артмаган, соңгыларының бәяләре кыйммәтләнгән.

– Бүгенгә социаль структураларны шикәр белән тәэмин итү, ярминкәләргә чыгару өчен запаслар булдырылды. Сәүдә үзәкләренә килгәндә, Зәй шикәр заводы – федераль челтәрләр белән, Буа заводы республика сәүдә челтәрләре белән килешүләр төзегән. Бәяләр бөтен Россиядә билгеле бер темплар буенча үсә, – диде министр.

Җитәкчеләр, товар кытлыгы юк, дип даими рәвештә сөйләп торсалар да, халык кибетләрдә аерым бер товарларның җитәрлек күләмдә булмавына зарлана. Марат Җәббаров тагын бер кат бу хәлне кирәкле товарларны тарату үзәкләреннән кайтарып өлгермәү белән аңлатты.

– Кайбер сәүдә челтәрләре шикәрнең бер кулга бирелә торган сату күләмен киметергә булды. Спекулянтлар күпләп алалар да, кыйммәтрәк бәядән сатып җибәрәләр. Әйе, андый проблема бар. Сәүдә челтәрләрен контрольдә тотабыз, алар күпләп шикәр алучыларны истә дә калдырырга тырыша. Спекуляция ярминкәләрдә дә булмасын дип, контрольдә тотачакбыз, – диде министр.

Моннан кала, узган атнада Евразия икътисади берлегенә керүче илләргә ашлык һәм шикәр чыгару тыелды. Монда сүз аерым алганда бодай, арыш, арпа һәм кукуруз турында бара. Марат Җәббаров әлеге чараның вакытлыча булуын әйтте.

– Бу карар бүгенге шартларда эчке базарны саклар һәм илне азык-төлек куркынычсызлыгы белән тәэмин итәр өчен эшләнелә. Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча, бүгенгә ашлык белән тәэмин ителеш 150 процентган артып китә. Моннан кала, Россия халыкны башка төр продуктлар белән тулысынча тәэмин итә. Чит илдән кертелә торган товарларга ихтыяҗ зур түгел. Ихтыяҗ булганнары да безнең илдә табигать шартларына бәйле рәвештә генә җитештерелми, – диде министр.

Аның каравы быел Татарстанда яшелчә һәм бәрәңге утырту мәйданнарын 10 процентка арттырырга уйлыйлар. Биш ел эчендә республикада яшелчә саклагычлар төзү буенча да зур эшләр башкару планнары бар. Башка культуралар буенча үзгәрешләр булмаячак. Марат Җәббаров фикеренчә, бүгенге шартлар үз җитештерүчеләребез өчен яңа мөмкинлекләр ача.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Барлык ярдәм чаралары үз көчендә калачак, – диде ул. – Шулай ук без продукция күләмен арттыру буенча эре җитештерүчеләр белән дә сөйләшүләр алып барабыз. Сөт һәм ит буенча мөмкинлекләр җитәрлек. Әйе, ашлык, ярма эшкәртү буенча проблемалар бар. Кооперативлар аша эшли алырлык берничә проектыбыз бар. Аларга ярдәм итәргә тырышабыз.

Соңгы ике атнада азык-төлек булмаган товарларга да бәяләр кискен артты. Сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Герман Лернер әйтүенчә, бигрәк тә кер юу порошогына, бәдрәф кәгазенә һәм подгузникларга бәяләр күтәрелгән. Ә менә шырпы, антисептик, бала ашата торган шешә хаклары, киресенчә, төшкән.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЧАЛЛЫНЫҢ ҮТКЕН КАЛӘМЛЕ КЫЗЫ

Журналист кебек язу-сызу эшләренә мөкиббән кешенең гадәттә әллә ничә һөнәре була: я язучылык эше бөтереп ала аны, я күңел түреннән шигырь юллары тама башлый, тарих төпкеленә дә төшеп китә. Чаллы шәһәрендә яшәп, 35 ел гомерен шушы һөнәргә багышлаган Илисә ГАНЕЕВА, мәсәлән, боларның барысына да өстәп, тагын да ераккарак киткән: нәсел җепләре турында шәҗәрәләр төзегән. Инде шул дәрәҗәдә остарган ки, аңа киңәш сорап килүчеләр дә байтак. Илисә ханым тәҗрибәсен безнең белән дә уртаклашты.

– Һичшиксез, моның өчен беренче чиратта вакыт кирәк. Мин бу эшкә уйламаганда-көтмәгәндә, пандемия башланып, үзизоляциягә күчкәч тотындым. Дөресрәге, кәгазьләремне тәртипкә салу нияте белән архивымны актарырга керештем. Баксаң, гаиләбез, туганнарыбыз турында язмалар шундый күп җыелган икән. Үзем дә шактый язганмын. Менә шунда аларны бергә туплау теләге уянды да инде.

:: Эшне нидән башладыгыз?

– Башта архивымны тәртипкә китердем. Барлык туганнарыма да шалтыратып, ниятемне белдердем. Кайберләре белгәннәрен үзләре язып бирде, өлкәнрәкләрен диктофонга яздырып алдым. Шушы хезмәтләрем генә дә нәселемнең 12 буын вәкилен табарга, күп туганым турында хикәят язарга ярдәм итте. Эзләнә торгач, авыл тарихы, төбәгебез турында бай гына материал тупланды. Алар барысы да «Җиңүче варислары» дип аталган китабыма керде. Архивымда тагын бер зур байлыкка тап булдым: әти-әни, туганнар, балалар язган хатлар. Шундый 100 хат табылды. Гадәти генә сүзләр булса да, хәзер аларны уку бик кызык, чөнки шул чордагы вазгыятьне чагылдыра, мин аларны тарихи документлар кебегрәк кабул итәм. Бу хатлар «Үткәннәрдән киләчәккә хатлар» китабына тупланды. Әле тагын 15 яшьтән алып барган көндәлегем дә килеп чыкты. «Яшьлегем көндәлеге...» дигән китапчыкны дусларыма өләштем. Ә бәләкәй туганнарым өчен ике әкиятне үз эченә алган китап бүләк булды. Ышанырлык та түгел, боларның барысын да мин пандемия чорында зур теләк һәм дулкынлану белән эшләп бетердем. Борчылып ятарга хәтта вакыт та тимәде. Иң мөһиме, үз нәселем турында шундый күп яңалыклар белдем һәм аны онытылмаслык, югалмаслык итеп теркәп куя алдым.

:: Нәсел башында торган бабаларыгыз Башкортстан якларына Татарстаннан күчеп киткән дип аңладым.

– Ачыкланган кадәренчә, безнең тамырлар 1682 елда туган Исай бабайдан башланган. Бабаларыбызның исемнәре буыннан буынга тапшырылып килгән, барысы да әтием блокнотында теркәп куелган. Без бәләкәйдән әтием сөйләгәннәрне тыңлап үстек. Ул ерак бабабызның Казан ханлыгында яшәгәнен әйтә килде. 1552 елда Явыз Иван Казанны яулап алгач, көчләп чукындырылудан качарга туры килгән. Башкорт җирләрендә төпләнеп калган. Хәзер инде туганнарыбызның күбесе Башкортстанда яши. Яшьләр арасында Казанга килеп төпләнүчеләр дә бар. Әйтергә кирәк, без кечкенәдән тарихи ватаныбызның Татарстан икәнлеген белеп, тоеп яшәдек. Газета-журналларны татар телендә укыдык, татар мәктәбендә белем алдык. Шуңа күрә үземнең дә Казан университетының журналистика бүлегендә белем алуым бик табигый.

:: Туганнарыгыз турында да шактый күп яңалыклар белгәнсездер, мөгаен?

– «Җиңүче варислары» китабына язылган 50 кеше – әтием Гайсә Гыйният улы тамырына кагылышлылар гына. Ә башка туганнарым төзегән нәсел шәҗәрәсендә ике меңнән артык кеше бар. Әтием Башкортстанның Стәрлетамак районы Кече Аллагуват авылында туа. Бөек Ватан сугышында катнаша. Өйгә 1946 елда гына кайта. Биш баланы аның беренче хатыны үстерә. Кызыклы эпизодлар очрый, әлбәттә. Үз авылларына фронтовик кайтуын ишеткән колхоз рәисе, каршы алырга дип, тарантаслы ат җибәрә. Хәрби киемле кеше: «Сез – кем малайлары?» – дип сорагач, яшүсмерләрнең берсе: «Газизов Гайсәнеке», – дип җавап бирә. Абыем Рифар була ул. Ата белән ул бер-берсен танымыйлар. Гаҗәп тә түгел. Алты ел вакыт узган була бит инде. Йорт янына килеп туктагач, әтием алдына куркыныч күренеш килеп баса. Түбәнең яртысын, киртә-кураларны утын урынына якканнар. Баштагы мәлдә аның башына хәтта, моны ничек торгызырмын, ник сугышта үлеп калмадым икән, дигән уй да килә. Әмма балалар мондый килде-китте уйлардан бик тиз арындыра. 1948 елны гаиләдә алтынчы бала – Вилур дөньяга килә. Аңа ике яшь тулганда, хатыны Өминур начар авырудан үлеп китә. Әтием алты бала белән тол кала. Мондый «байлык» янына килергә озак вакыт беркем дә җөрьәт итми. Шулай да берсе табыла. Ул – минем әнием Әминә. Гаиләдә тагын өч кыз дөньяга килә. Шулай итеп, тугызау булабыз. Шунысы кызык: абыйларым белән апам Зәкиянең әти ягыннан гына туган булуын мин бары тик зур үскәч кенә белдем. Безнең арада гел җылы мөнәсәбәтләр генә. Элек тә, хәзер дә шулай...

Нәселебездә легендар кешеләр дә бар. Мәсәлән, Әдһәм бабай Газизов. Ул Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша. Әсирлеккә төшә. Аны ач үлемнән бер немецның батраклыкка алуы гына коткара. Бабай җир казып, бакчада эшләп кенә калмый, немец агротехникасын өйрәнә башлый, вакыты булганда туган илне, якыннарын сагыну хисләре белән сугарылган бәетләр иҗат итә. Соңрак шул бәетләрнең берсе Татарстан Фәннәр академиясе чыгарган халык иҗаты энциклопедиясендә дә урын ала. Туган илгә кайткач, ул, немецлардан үрнәк алып, тирә-якта күрелмәгән яшелчә бакчасы үстерә. Сука кебек җиһазларны да шундагыча ясый. Тик икешәр данә итеп. Берсен үзенә калдыра, икенчесен башкаларга бирә, авылдашлары чират торып эшлиләр. Ишегалдында буралы коесы да була. Су алырга шунда йөриләр. Кул тегерменендә бөртек тартырга да шунда киләләр. Киңәш кирәк булса да, орлык-үсентеләр дигәндә дә, Әдһәм бабамның капкасы ябылып тормый. Беренчеләрдән башлап умарта үрчетә башлый. Аны авылдашлары кунакка чакырырга, әсирлектә язган шигырьләрен сөйләтергә яраталар. Ә үзләре күз яшьләре белән елап утыралар. Ул тартмый, эчми, беркем белән дә бәхәсләшми, беркемнән дә көнләшми. Аның бу дөньяны ташлап китүен дә легенда кебек сөйлиләр. Беркөнне иртә белән чәй эчәргә утыргач, бер йотым да каба алмый. Диванда газета укып утырган хатынына йомшак кына: «Кил, якынрак утыр әле. Мин бүген китәм бит, балаларны да чакыр», – дип әйтә. Аңа 93 яшь була.

:: Димәк, хезмәт сөючәнлек, яңалыкка омтылыш нәселегездән килә. Сезнең шундый киңкырлы эш алып баруыгызга гаҗәпләнәсе дә юк.

– Мин кечкенәдән журналист булырга хыялландым. Әмма әти-әнием Салават педагогия училищесына керүемне теләде. Авылда берничә ел башлангыч сыйныфларда укытканнан соң да хыялымны җиңә алмадым әле. Стәрлетамак район газетасында эшли башладым. Аннан Казанга укырга килдем. Минем бөтен иҗатым КамАЗ, Чаллы шәһәре белән бәйле. Башта заводның радиотапшырулар редакциясендә эшләдем. 1997 елны Татарстанда беренчеләрдән булып бәйсез «Кама-Пресс» агентлыгы оештырдым, аның директоры булдым. Аннан «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенә үзхәбәрче булып күчтем.

Илисә ханым тыйнаклык йөзеннән гадәти эш урыннарын гына санап чыкты, әлбәттә. Шуның белән бергә төн йокыларын калдырганнары да бихисап әле. Ул берьюлы диярлек республика, федераль матбугат чараларында эшли. КамАЗ җәмгыятенең кою заводы турында китап яза. 2000 елда Халыкара хатын-кызлар проектлары конкурсында җиңү яулый. Грант отып, әнисе Әминә апа һәм тагын олы яштәге 9 хатын турында китап чыгарырга өлгерә. Җиде дистәсен тутырырга җыенса да, каләмен кулыннан төшергәне юк. Бүләкләре дә бихисап. Мактау кәгазьләре, «Социалистик ярышта җиңүче» билгеләре, «Яр Чаллы шәһәренә күрсәткән хезмәтләре өчен» медале, «Минем Чаллым» бәйгесендә ел саен диярлек төрле номинацияләрдә җиңү яулаулар. Бер караганда, Чаллыда гына хезмәт иткән кебек, әмма республика, ил казанышларында аның бик зур өлеше бар.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Фатир алу да – онлайн

Яңалык

Хәзер социаль ипотека алырга документ тапшырам дип су буе чират көтәсе түгел. Фатир шартларын яхшырту өчен, чиратка онлайн да басып була. Иң мөһиме – интернетың эшләсен дә кул астыңда кирәкле документларың булсын. Бу хакта «Татар-информ» агентлыгында узган очрашуда сөйләделәр.

– Татарстан Президенты каршындагы Торак фондына моңарчы да электрон рәвештә язылып була иде. Шулай ук сайт аша айлык түләүләрне дә башкару мөмкинлеге бар. Инде хәзер фатир алу өчен чиратка басуны да электрон рәвештә башкарып була. Әлеге хезмәт быел гына эшли башлады. Инде фатирга чиратка куюны сораган 200 гариза килеп иреште, – ди Татарстан Президенты каршындагы Торак фондының башкарма директоры урынбасары Булат Гыйльманов.

Аның әйтүенчә, электрон документ тапшыру эшне күпкә җиңеләйткән. Бу, беренче чиратта, торак шартларын яхшыртырга теләүче кеше өчен уңайлы, ди ул. Электрон рәвештә мөрәҗәгать иткәндә, система кайбер документларны сорап та тормаска мөмкин. Әйтик, гариза бирүче «Дәүләт хезмәтләре» порталында теркәлгән икән, бу очракта аның хакында мәгълүматның күбесе әзер инде. Торак фонды ул язуларны аннан ала. Бу кәгазь боткасыннан коткара. Хәзер чиратка басканда сорала торган БТИ кәгазе дә кирәкми. Фатир алу өчен чиратка куюны күпфункцияле үзәкләр аша да эшләп була. Интернет белән дус булмаганнар, өлкән яшьтәгеләр биргә килә ала. Әмма журналистлар арасында МФЦга барып, фатирга чиратка баса алмыйча кайтучылар да бар икән. Казанның торак сәясәте идарәсе җитәкче Ренат Шәмсетдинов әйтүенчә, бу – яңа хезмәт, әлегә барысы да өйрәнә.

Очрашуда илдәге вазгыятьнең торак төзелешенә зыяны булмасмы, дип тә сораштылар. Булат Гыйльманов борчылмаска куша.

– 2007 елдан бирле социаль ипотека ставкасы 7 процентны тәшкил итә. Аны арттырырга җыенмыйбыз. Алдан алган ипотеканың да процент ставкасы үзгәрми. Беренчел кертем дә шул килеш кала: торак бәясенең 10 процентын тәшкил итә. Быел төзелеп беткән һәм төзелеп бетәчәк фатирларда бер квадрат метрның бәясе 54 мең сум кала. Яңа төзелә башлаячак йортларның бәясен әлегә әйтә алмыйбыз, – ди ул.

Булат Гыйльманов социаль ипотека түләвен киметер өчен ана капиталын куллану турында да сөйләде:

– Ана капиталы акчасы белән бурычын киметүне 4 мең гаилә көтә. Ел саен республикада яшәүче 3 мең 500 гаиләне торaклы итәбез. Ипотекага чиратка баскан гаиләләр, балалары тугач, 200 мең сум акчага да өметләнә ала, – ди Булат Гыйльманов.

Очрашуда социаль ипотека буенча фатир кемнәргә тиеш дигән сорауга да җавап эзләделәр. Элек ипотека алу өчен бюджетта эшләү шарт булса, хәзер «Яшь гаилә» программасы буенча фатир алырга була. Монда инде бюджетта эшләү мәҗбүри түгел. Яшь гаиләдәге берәрсенең 36 яшькә җитмәгән булуы кирәк. Шулай ук оешмаларда эшләүчеләр дә ипотекага өметләнә ала. Һәр оешманың үзендә торак комиссиясе эшли икән. Алар үзләре кайсы эшчегә фатир кирәклеген хәл итәләр. Һәм ул гаилә оешма ярдәме белән фатир ала. Әгәр кеше тулай торакта үзе генә яшәсә дә, ул да ипотекага чиратка баса ала. Фатир мәйданы бер кеше өчен – 33, ике кеше өчен – 42, өч кеше өчен 54 квадрат метр булырга тиеш. Әгәр кимрәк икән, кеше торак шартын яхшырта ала. Берүзе генә фатир алган кешегә ул кыйммәткә чыга. Булат Гыйльманов аңлатканча, коэффициент үзгәреп, торакның бер квадрат метр мәйданы 54 мең сум түгел, 64 меңне тәшкил итә.

– Торак алуның үз тәртибе бар. Моның өчен районнарыгыздагы торак сәясәте бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Әгәр чиратка басар өчен каршылыклар бар икән, сезгә бу хакта аңлатма киләчәк. Сез моның белән риза түгелсез икән, аны суд аша хәл итә аласыз. Тагын шунысы бар: ипотекага чиратка басканда документ сорауның үз тәртибе бар. Әйтик, районда йортыгыз булса, Казанда фатир ала алмаячаксыз. Кабатлап әйтәм: социаль ипотека торак шартларын яхшырту максатыннан бирелә, – ди ул.

Якын киләчәктә йортлар «Салават күпере», «Сандугач» торак комплексында төзеләчәк. Анда төзелеп беткәч, Республика клиник хастаханәсе янәшәсендәге «М12» торак комплексын сала башлаячаклар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТРЕНЕР СӨЛӘЙМАН ГАЛИУЛЛИН:

«ҺӘР БАЛАДАН ШАХМАТЧЫ ЯСАП БУЛА»

Күптән түгел Арча районының Ашытбаш мәктәбендә укучылар арасында шахмат буенча республика беренчелеге узды. Әлеге ярышны оештыручы Сөләйман Галиуллин, теләсә кемнән шахматчы ясап була, дигән фикердә. Аның әйтүенчә, Пифагор теоремасын шахмат тактасында аңлатырга 3–4 минут вакыт җитә. Хыяллары зурдан тренерның, тик аннан гына тормаган сәбәпләр дә бар.

Сөләйман Галиуллин – Ашытбаш егете. Түбән Новгородта Хәрби инженерлар академиясен тәмамлаган. Хәрбилектән киткәч, Вологда шәһәрендәге укыту-җитештерү комбинатында техник нормалаштыру, агач эшкәртү, төзелеш кебек фәннәрдән укыткан. Программаларын да үзе язган. Әмма озак укыта алмый, чөнки өлкән яшьтәге әти-әнисен карарга туган авылына кайтырга туры килә. Тормыш көтәргә кирәк дип, 50 яшендә Арча педагогика көллиятендә физкультура укытучысы белгечлеге ала. Аның 16 спорт төреннән разряды бар. Көрәш буенча спорт остасына кандидат һәм Көнчыгыш спорт төрләре буенча кара билбау иясе ул.

Авылда аның турында, белмәгән, кызыксынмаган нәрсәсе юк, диләр. Тарихи язмалар яза, бакчачылык, терлекчелек белән шөгыльләнә. Үзенең Галиуллиннар буынының 21 нче вәкиле икәнен дә дәлилләгән. Шахматка һәвәслеге нәселдән килә. Шуңа күрә кечкенә Сөләйман гына читтә кала алмаган. «Шах», «мат» дигән төшенчәләрне 3–4 яшьлек вакытта ук ишеткән. 7–8 яшьтә исә аны авыл агайлары ярышларга кертми башлаган. Югыйсә барысының да борыннарына чиртәчәк! Заманында Татарстан турнирларында җиңү яулаган. Моннан өч ел элек авыл мәктәбендә укучыларга шахмат түгәрәге оештырган. Тик штат бетерелгәч, турнирны оештыручы буларак кына катнаша. Авылларда шахмат төрен үстереп, чемпионнар тәрбияләү турында хыяллана ул. Әлбәттә, моның өчен түгәрәкләр булдырырга, аны өйрәтә алырдай белгечләр кирәк.

– Шахматка өйрәткәндә, аны башка фәннәр белән бәйләп аңлатам. Биология, физкультура, математика... Фикерләү дәрәҗәсен арттыру өчен нинди күнегүләр ясарга кирәклеген күрсәтәм. Мәктәптә арифметика укытылмый, шахмат исә кара исәпкә, фикерләргә өйрәтә. Математика дәресендәге кебек язып-сызып аңлатырга кирәкми. Бала сәгатькә карап эшли башлый һәм өендә дә вакытын дөрес итеп бүләргә өйрәнә. Хикмәтле уен бу. Гомумән, өстәмә белемнең кайсын гына алсаң да, җырмы, биюме, туризммы – һәркайсының нигезендә тәрбия, хезмәт, сәламәтлеккә өйрәтү ятарга тиеш, – ди Сөләйман әфәнде.

Үзе сөйли, үзе: «Артык хисләнеп китмәдемме, дөресе шул бит аның!» – дип куя. Бу урында Пошалым чаналары, бишекләр ясаган данлыклы бабайларын, киез итек баскан әтисе Вәгыйзьне искә төшерде. Кукмара итекчеләренең әтисе янына кислотасыз итек басканны карарга килүен дә хәтерли. Бабалары – кәсепчеләр. Шахмат уйнауның исәп-хисап эшендә дә файдасы тигән. Шуңа күрә Сөләйман Галиуллин шахмат белән дус булган балалардан менә дигән эшмәкәрләр, кәсепчеләр чыгачагына ышана.

Мәктәптә түгәрәге калмаса да, укучылар белән элемтәсен өзми, районда шахмат, шашка турнирлары үткәрүен дәвам иттерә тренер. Авыл балалары зыялы, киң карашлы булып үссен өчен үз көчен кызганмый. Ә эшләгән кешегә күпмедер хезмәт хакы түләсәләр, әллә кайчан чемпионнар тәрбияләр идек, ди. Гомумән алганда, шахмат ярышларында күп дигәндә, 100дән артык укучы катнашкан. Моңа кадәр ярышны Яңа Кенәр авылында оештырсалар, быел җиденчесен Ашытбаш мәктәбендә үткәргәннәр.

– Авылларда шахмат беренчелекләрен уздыручы мәктәпләр юк. Актанышта уза, әмма ул – район үзәге. Быел безгә 17 команда килде. Һәрберсендә – ике малай, бер кыз. География киң: Балтач, Сабадан башлап, Актаныш, Ютазы районнарына кадәр. Кукмара командасы беренче урында булса, Актаныш, Саба яшьләре икенче, өченче урыннарны бүлеште. Тиздән мәктәптә шашка ярышлары үтәчәк, бу чарага да чакырабыз, – ди Сөләйман Галиуллин.

Сәрия МИФТАХОВА

Спорт

Келәм күрсәтер

Җәлил истәлегенә

Газетабызның көрәш бәйгесе башланырга санаулы көннәр калып бара. Пәнҗешәмбе батырлар Казанга җыела. Турнир җомга көнне ачыла, ә шимбә Муса Җәлил бәйгесенең быелгы җиңүчеләре ачыкланачак.

1964 елның көзендә Казанның «Динамо» җәмгыяте спорт залында үткәрелгән ярышта 11 командадан иллеләп көрәшче катнашкан. Икенче елны исә командалар саны – 24кә, ә катнашучылар саны 91гә җиткән. 1966 елда исә 30 районнан 121 пәһлеван җыелган, шулай итеп, алар гел артып барган.

Шул еллар эчендә газетада чыккан язмаларда үзләре тарих булырлык кешеләрнең исемнәре байтак. Әйтик, Бөек Ватан сугышы ветераны, Ленинград фронтында кыю минометчы булган Зөфәр Ханов 1965, 1968 елларда чемпион исемен алган. Ә бит икенче тапкыр батыр калганда аңа 43 яшь булган! Зөфәр Ханов 1970 елда да газетаның махсус призы белән бүләкләнгән. Әлеге легендар батыр үзенең 55 яшен дә келәмдә көрәшеп каршылаган… Республикабыздагы авыл спортчыларыннан «Татарстанның атказанган физкультура хезмәткәре» дигән исемгә лаек булган беренче кеше ул.

Көрәшчеләр Җәлил бәйгесендә җиңеп кенә калмый, әлеге турнирның тарихын да яза. Тарих димәктән, Чаллы көрәшчесе Айрат Гыйлаев бу ярышта 12 мәртәбә батыр калып, әле дә рекорд иясе булып санала. Балтачтан Айдар Хәйретдинов 10 мәртәбә җиңүче булып танылды. Балык Бистәсеннән Илнар Әхмәтҗанов 9 тапкыр батыр калды. Әлмәт пәһлеваны, ике ел элек мәрхүм булган Ильяс Галимов та 9 тапкыр җиңү яулады герой-шагыйрь истәлегенә уздырылган ярышта. Теләчедән Раил Нургалиев исә тагын бер мәртәбә батыр калса, Айдар абыйсын куып тотачак.

Ульян пәһлеваны Сергей Павлик исәбендә 7 җиңү бар. Алты тапкыр җиңүчеләр арасында без Балтачтан Фидаил Шакировны, Питрәчтән Рафаил Сафиуллинны, әле дә келәмдә ут уйнатучы Ренас Кәлимуллинны (Теләче) күрәбез. Данил Галиев, Гакыйф Борһанов (икесе дә – Түбән Камадан), Ранил Габдрахманов (Балтач), Илдар Аббасов (Биектау), Айдар Нәҗметдинов (Минзәлә), Муса Галләмов, Артур Зөлкарнәев исәбендә бишәр тапкыр батыр калу шатлыгы бар. Дүрт тапкыр җиңүче исемен яулаучылар: Рәшит Сәмигуллин (Казан), Фазыл Әхмәтҗанов (Түбән Кама), Михаил Чернов (Питрәч), Илгиз Гайнуллин (Яшел Үзән), Марсель Таһиров (Әтнә), Рафак Хәлиуллин (Теләче), Рифкать Хөсәенов (Балтач), Фарил Фатыйхов (Мамадыш), Рөстәм Гыйниятов (Питрәч), Хәмит Вәлиев (Чаллы), Наил Хәмидуллин (Теләче), Рафил Сабиров (Саба), Илшат Сибгатуллин (Чаллы), Ришат Гайнетдинов (Минзәлә), Руслан Нургалиев (Әлмәт), Ринат Хәйретдинов (Балтач), Лениз Абдуллин (Казанның Вахитов районы).

Узган ел батыр исемен яулаган егетләрнең хәлләрен белешүне дәвам иттерәбез.

Илсур ГЫЙМАДЕТДИНОВ (Кукмара):
– Быел да җиңәргә дип киләбез инде, Алла боерса. Беренче тапкыр яшем керүгә, ягъни 18 яшьтә үк катнашкан идем, инде 31не тутырдым. Быел 11 нче килүем микән – төгәл генә әйтә дә алмыйм. Биш-алты мәртәбә пьедесталга мендем. Татарстан чемпионаты белән бер дәрәҗәдә, дияр идем мин Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы турнирны. Татарстан гына түгел, чит төбәкләрдән килүчеләр дә шактый. Узган ел турнирның уздырылу вакыты минем өчен мөһим булган берьюлы ике вакыйгага туры килде. Беренчедән, турнирга 10 көн вакыт калганда, кызыбыз туды. Җиңүемне аңа багышладым. Икенчедән, үземнең туган көнгә дә бүләк ясадым. Быел кызым янына тагын бер бүләк белән кайтмый булмас. Әле бит узган ел Ильяс абый Галимов истәлегенә булдырылган махсус бүләкне дә миңа тапшырдылар. Анысы тагын бер зур сөенеч булды.

Илназ МИҢМУЛЛИН (Балтач):
– Башта, быел турнир булмый, дигән хәбәрләр ишетелгән иде, шуңа күрә аеруча көтеп алабыз. Гомумән, кечкенә чакта да көтеп ала идек без аны. Электән спорт дөньясындагы зур ярышларның берсе буларак хәтергә сеңеп калган. Ялгышмасам, бу юлы әлеге турнирда дүртенче катнашуым. Башта – өченче, аннан – икенче урыннарда калсам, узган ел батыр исемен яуладым. Хәзерге вакытта Казанның энергетика университетында магистратурада укыйм. Яңалыкларым әллә ни юк. Тик йөрәгем буш түгел, укып бетерү белән, өйләнергә инде исәп.

Илнар ГАЛИМОВ (Алабуга):
– Быел, ялгышмасам, җиденче мәртәбә катнашам. Елдагыча, җиңәр өчен киләбез. Бер тапкыр – өченче, ике тапкыр – икенче булдым һәм ике мәртәбә батыр калдым. Элек бу турнир Чаллыда уза иде бит. Яшьләр арасында көрәшеп йөргән чакта, Алабугадан карарга килә идек. Ул чакта келәмне Айрат Гыйлаев кебек көчле көрәшчеләр тота иде. Аларның матур алымнары канга сеңгән инде. Гомумән, бу турнир электән безнең телдән төшмәде ул. Монда батыр калу – үзгә бер абруй казануга тиң. Быел келәмгә яңа статуста – ике бала әтисе буларак та чыгам. 2021 елның өченче декабрендә улыбыз Самид туды. Башка яңалыкларым юк – бар да бер көйгә.

50 ЕЛ БЕРГӘ ГОМЕР ИТҮЧЕ БАБАНИЯЗОВЛАР:

«ТИЗ КАБЫНАБЫЗ, ТИЗ СҮНӘБЕЗ»

Үрнәк гаилә

Лена апа белән телефоннан сөйләштек. Күп булса, ярты сәгатьләп гәпләшкәнбездер инде – шул кыска арада яшәвенең асылын да, тормышының матурлыгын да гади генә итеп сөйләп бирде ул. Чөнки ул гади нәрсәләрдән дә тәм табып яши белә. Лена апа белән Әлфәт абый Мамадыш районының Югары Ушма авылында гомер кичерә. Быел гаилә коруларына 50 ел була икән.

«Лена апа, Әлфәт абый белән ничек таныштыгыз?» – дим, сүзне башлап. Ә аңа башкасы кызык әле. «Кызым, тавышың бик яшь кебек, эшли генә башладың мәллә?» Сорагач, бераз үзем турында да сөйләдем инде.

– И җаным, безнең яшьлек тә шундый матур иде бит! Мамадыш районының Югары Сон авылы кызы мин. Мәктәпне тәмамлауга, укытучы булып эшли башладым. Ул чакта андый мөмкинлек бар иде. Үзем читтән торып укырга да кердем. Кая ул вакытта кияүгә чыгу турында уйлау! Тормыш мәшәкатьләренә кереп чумсам, укуымны тәмамлый алмам, дип курыктым. Ә башка кызлар бер-бер артлы кияүгә чыга торды. Ә мин, тәвәккәлләп, тере урыс та күрмәгән башым белән Казанга чыгып киттем, – дип, яшьлек хатирәләрен яңартырга тотынды әңгәмәдәшем. – Яңадан укырга кердем. Бу юлы көндезгә бүлеккә. Башта бер әбигә фатирга кереп тордым. Ул әбине әле дә хәтерлим мин: усал һәм таләпчән карчык иде. Оныгың һәм тагын өч квартирантка белән яшәсәң, башкача булмыйдыр шул. Бер атнага бер кызны җыештыру эшләренә җаваплы итеп куя иде ул. Берсендә шулай идән юып йөрим. «Вот, посмотрите на татарочку! На совесть работает», – дип әйтеп куйды әбиебез, башка кызларга эндәшкән булып. Имеш, тегеләр өстән-өстән генә шомартып йөриләр, ә мин җиренә җиткереп юганмындыр инде…

«Машинасына да кызыкканмындыр…»

Аннан тулай торакта да яшәгән Лена апа. Рәхәт, күңелле тордык, ди. Ә Югары Ушмага укуын тәмамлагач кайткан. «Завучлары киткән чак иде, югары белемем булгач, аның урынына мине куйдылар». Әлфәт абый исә бер ел алдан кайткан була. «Мамадышка, ЮХИДИ идарәсенә барып эшләгән мәле иде аның. Ә минем Мамадыш – Казан юлын таптап арыган чагым. Хәзер генә балалар уч төбеннән төшми, ә без «абый, утырт әле»не ятлап бетергән идек. Ә Әлфәт абыегызның машинасы бар иде. Моңа кияүгә чыксам, үземә дә, балаларыбызга да олы юлга чыгып китү ансат булачак, дип уйладым инде үземчә. Үзе дә озаткалады. Бер ел йөргән булдык та, өйләнешеп тә куйдык», – дип, шул чакларны искә алды Лена апа.

Әлфәт абый үзе без шалтыратканда өйдә түгел иде. «Тәрәзә төбем тулы помидор минем, инде чәчәк атарга әзерләнәләр. Шуларга савытлар ясарга дип чыгып китте бабай», – дип аклап куйды аны әңгәмәдәшем.

Кавышканда икесенә дә 25 яшь булган. «Хәзер инде олы кызыбыз 50 яшен тутыра. Узган гомер, диген… Бик бай әти-әни без – Алла биргән өч кызыбыз бар, өчесе дә Мамадышта яши. Төпчегебез әтисе юлын сайлады – милициядә кадрлар бүлеге җитәкчесе урынбасары, подполковник. Берсеннән-берсе тәмле җиде оныгыбыз да бар», – дип, гаиләсе белән таныштыруын дәвам итте Лена апа.

«Әлфәтнең «матае»нда мин дә элдердем…»

– Тормыш булгач, төрле хәлләр була бит. Әйткәләшкән чакларыгыз буламы? – дип сорыйм Лена ападан.

– Йолдызлык буенча без икебез дә – Арыслан. Ырлашабыз, ырлашабыз да дуслашабыз. Безнең шулай әйткәләшкәнне карап торган кеше: «Сезнең ызгышуыгыз да кызык бит», – дип кызыга безгә. Йә миңа нәрсәдер ошамый, йә аңа. Икебез дәшми кала алмыйбыз. Ләкин чәй табынына утырганда ул ызгышулар онытыла – берни булмагандай чөкердәшәбез. Тиз кабынабыз, тиз сүнәбез. Берничә көн буе сөйләшми йөрү… юк-юк, андый чаклар булмады, – ди ул, көлеп.

Өйләнешеп, бергә тора гына башлаган елларда Әлфәт абый кайтып кермәгән диярлек. Ул чакта алар ЮХИДИда бөтен районга өч кенә кеше булган. «Башта «матай»да чыгып чаба иде. Аннан ул «матай» миңа да эләгә башлады. Җыелышларга да, башкасына да утырам да чыгып чабам. Балаларны утыртып җилдергән чаклар да булды».

Ул чакта алар Әлфәт абыйның әти-әнисе белән бергә яшәгән. Башкалар хәтта көнләшеп тә караган аларга. «Шундый яхшы яшәдек. Безнең әткәйнең таләпчән кеше булуын бөтен авыл белә иде, ә без килешеп яши белдек. Арага сүз кыстырып караучысы да булды инде. Котыртучылар беткәнмени. Юк, ышанмадым мин аларга. Әлфәтне яманласалар, үзеннән сорый идем дә, үзе ни әйтә, шуңа ышана идем. Ул мине, мин аны көнләп яшәмәдек», – дип, тормышының гөрләп торган чакларын искә алуны дәвам итте әңгәмәдәшем.

Лена апа хуҗалык эшләрен дә Әлфәт абыйга ышанып тапшырган. Акчаны элек тә кесәдә тотмый идем, хәзер дә шулай, ди. Бөтен кирәк-яракны Әлфәт абый ала, башкасына да, тиененә-тиенен җиткереп, үзе түләп бара икән. Ә бакча эшләре өчен Лена апа җаваплы. «Җәй көне шуннан кермим инде», – ди.

«Бәхетне читтән эзләмәскә кирәк…»

– Яшьләр арасында аерылышучылар күп, Лена апа. Сезнең кебек тигез гомер итүнең берәр сере бармы? – дим аңа.

– Аның серен белүче, менә дигән киңәш бирә алучысы булса, аны табарлар иде дә, телдән-телгә йөртеп, берәү дә аерылышмас иде… Юк шул аның сере. Ныклы никах күкләрдән биреләрдер ул, аннан, тагын бик күп нәрсәләрдән торадыр. Яратуның иң югары ноктасы – балаларга карата мәхәббәт. Кешенең чәчәк атар чагы була. Ягъни яшьлек инде ул. Аннан җимешләр җыяр чак җитә, ягъни үз балаларыңны тәрбиялисең. Һәр чорның кадерен белергә, бәхетне читтән эзләмәскә кирәк. Булганын яхшыртыйк, кадерен белик, – дип җавап бирде Лена апа.

Әңгәмәдәшем бүген үз тормышыннан бик канәгать. «Гомеремнең бер генә минуты да әрәмгә китмәде. Мин укытучылар кадерле чакта эшләп, тормышның иң дәртле чагында яшәп калдым. Беркайчан да үзем турында гына кайгыртмадым. Зарланмадым, ә уфтанып утырган кеше янында әле дә озак тора алмыйм. Хәрәкәттә – бәрәкәт, дип тә юкка әйтмиләр, гел нидер эшләп торырга кирәк. Яшьрәк чакта бик яратып бии идем мин, авыл укытучылары белән концертлар да куйдык. Әле хәзер дә, берәр матур җыр ишетсәм, бии башлыйм».

Лилия ГЫЙМАЗОВА

АНАНАС ҮСТЕ, ЧИРАТТА – ПОМЕЛО

Соклану

Башкортстанның Ярмәкәй районы Искешах авылында гомер итүче Флүзә Хәлиуллина белән безне социаль челтәрдәге сәхифәбез таныштырды. Ул үстергән чәчәкләрнең сурәтләре янынннан тыныч кына үтеп китеп булмый шул. Өстәвенә җылы якларда үсүче җимешләрне дә утырта икән. Ананасны үстереп ашаганнар инде, хәзер помело өлгергәнне көтәләр.

– Искешах авылына 38 ел элек килен булып төшкән идем. Салада эш сайлап тормыйсың, нәрсә кушалар – шуны эшлисең инде. Клубта да эшләдем, каенанам белән сарык та карадым, колхозда сыер да саудым, казлар да үстердем, чөгендер басуында да бил бөктем. Ә чәчәкләр үстерүдән җаныма рәхәтлек таптым, – дип башлады ул сүзен. – Чәчәк белән җенләнү – әниемнән күчкән шөгыль. Балачактан ук гөлләр ярата идем. Әниемнең салкын кышкы айларда да гөлләре шаулап чәчәк атты. Авыл кешеләре кызыгып, гөл ботакларын сорап, еш килде. Берсен дә кире бормады. Без матурлык арасында үстек. Үзем дә авылның иң матур урынында яшим, янәшәбездә күл, йортыбыз тау башында утыра. Өем тулы гөлләр, бакчам тулы чәчәкләр минем. Яшелчәләрем дә шаулап уңа. Әле менә теплицага 50 төп кыяр утырттык. Аны җылытып торабыз.

Флүзә апа – биш бала анасы. Дүртесенең үз тормышы икән инде. Төпчек балаларын гына башлы-күзле итәсе калган. Оныкларын исә чит ил җимешләрен үстереп сыйлый ул. Күптән түгел үзләре үстергән ананастан авыз иткәннәр.

– Ул ананасны ял итәргә баргач, Гоадан күчтәнәч итеп алып кайткан идем. Февраль ае булса да, яшел өлешен

суга утыртып карадым. Акрынлап тамыр җибәрде, җәй башында теплицага күчердем. Берзаман ананас чәчәк атты. Башта җимеш бирүенә бик ышанып та җитмәдек. Ә аның чәчәге җимешкә әйләнә башлады, җимеше зурайгач, сабагы кипте. Җитешкәндер дип аны кисеп алдык. Ананасыбыз 1 ел да 8 ай эчендә өлгерде, – ди Флүзә апа. – Помело орлыгын да утыртып куйган идек. Анысы да үсеп килә. Җимешен алып булырмы, белгесез. Мин бит ул җимешләр өчен махсус берни сипмим. Ашлама да кулланмыйм. Су сибәм дә, йөрәк җылымны кушам. Шуның белән үсәләр.

Флүзә апа кая барса да, гөлләрне күзли, ошаганнарының чыбыкчасын алып кайта. Мисырдан бугенвиллия дигән чәчәкнең 14 ботагын алып кайта. Аларның берсе генә тамыр җибәреп үсеп китә.

– Өемдә дә, бакчамда да гөлләр, чәчәкләр күп. Хризантеманың гына да 50 төре бар. Нәрсәләр үстерәсез, дигәнгә җавап биреп бетерә алмыйм. Интернетта нәрсә күрәм, шуңа заказ бирәм, – ди ул.

Флүзә апаның шөгыльләре бихисап. Барысы да чәчәкләргә бәйле. Үзе әйтмешли, аңа чәчәк кенә булсын. Тереме, юкмы – мөһим түгел. Интернеттан өйрәнеп, ефәк тасма белән чәчәкләр дә чиккән ул. Әле дә, сорап килүче булса, эшләп бирә.

– Ефәк тасмадан ясаган картиналарым да бар. Аларны сатып алучылар күп булды. Шулай ук интернеттан өйрәнеп, төсле кәгазь белән дә чәчәкләр ясый башладым. Ул эшләремне күргәзмәгә дә йөрттеләр. Әйтәм бит, мин – чәчкә җанлы кеше. Әле ярый ирем сүз әйтми. Бөтен эшне бергә эшлибез. Иремнең кулы алтын. Бакчада бер кул эше калмады. Бар эшне үзе ясаган тракторы белән башкара. Миңа бик булыша, – ди Флүзә апа.

Алар чәчәк белән яшелчәне дә мулдан үстерәләр, күп итеп мал да тоталар, кош-корт та асрыйлар. Ял итәргә, күңел ачарга да вакыт табалар. Флүзә апа клубтагы чараларда да актив катнаша.

– Тормыштан ямь табып яшәргә кирәк. Чәчәкләр арасында яшәп, начар уй уйламыйсың. Матурлык яшәргә көч бирә. Мин бик тә бәхетлемен, – ди ул. – Кулы эш белгән кеше югалып калмый. Иренмәскә генә кирәк. Хәзер бит интернет барысына да өйрәтә. Кулыңа эш тоту – җан рәхәте. Аллаһы Тәгалә эштән аермасын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 236

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+